**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕТУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ТОРМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422372 с. Большая Турма, ул. Ахметзянова, 87А

422372 Олы Тормы авылы, Әхмәтҗанов урамы, 87А

тел. (84373) 5-73-12, e-mail: b.turma@mail.ru
ОГРН 1061672018231, ИНН/КПП 1638005026/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16.09. 2024** **№ 22**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында" 2020 елның 14 апрелендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында" 15.06.2022 ел, № 1081 карарына ярашлы рәвештә Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге Башкарма комитетының 14.04.2020 № 8 карары белән расланган «2020 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә» түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 3 пунктта", муниципаль программаларның структур элементларын" сүзләрен төшереп калдырырга.;

2) 12 пунктның икенче абзацында", муниципаль программаларның структур элементларына" сүзләрен төшереп калдырырга.;

3) 12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламалар куллану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яисә түләүчеләрнең гомуми санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана торган бирелгән ташламаларны түләүчеләрнең ихтыяҗы";

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Н.Г.Салихов